КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 июня г.Казань № 723

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «М.Җәлил исемендәге Республика премиясе турында» 1997 ел, 27 июль, 175 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 11 март, 149 нчы; 2015 ел, 16 февраль, 95 нче; 2019 ел, 8 февраль, 83 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1254 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1048 нче; 2023 ел, 15 февраль, 149 нчы; 2023 ел, 29 март, 373 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комитет составыннан С.А.Мостафинаны чыгарырга;

Комитет составына Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары Айгөл Азат кызы Сабированы кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 884 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2020 ел, 17 март, 192 нче; 2020 ел, 14 июль, 590 нчы; 2020 ел, 5 август, 656 нчы; 2020 ел, 28 декабрь, 1203 нче; 2021 ел, 7 октябрь, 959 нчы; 2021 ел, 7 декабрь, 1180 нче; 2022 ел, 12 март, 224 нче; 2022 ел, 31 октябрь, 1161 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

3.3.63 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.63. Документларны карап тикшерә һәм Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларның Татарстан республикасы Җир кодексы кушымтасында билгеләнгән критерийларга туры килүе турында мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын, шулай ук мондый объектлар һәм проектлар параметрларына үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлылыгы турында мотивлаштырылган бәяләмәләр проектларын килештерә;»;

3.3.64 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.66 – 3.3.72 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.66. Россия Федерациясенең Татарстан Республикасындагы матди булмаган этномәдәни байлыгы (алга таба – матди булмаган этномәдәни байлык) объектларын ачыклау, өйрәнү, файдалану, актуальләштерү, саклап калу, популярлаштыру буенча чаралар күрә;

3.3.67. Матди булмаган этномәдәни байлык объектларын ачыклау, өйрәнү, файдалану, актуальләштерү, саклап калу, популярлаштыру өлешендә мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган федераль дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениеләреннән тыш) ярдәм чараларын оештыруны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

3.3.68. Матди булмаган этномәдәни байлык объектын Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары реестрына яки федераль дәүләт реестрына кертү турында заявкалар кабул итә;

3.3.69. Матди булмаган этномәдәни байлык объектын «Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни байлыгы турында» 2022 елның 20 октябрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни байлыгы федераль дәүләт реестрына кертү турында тәкъдимнәр бирә;

3.3.70. Матди булмаган этномәдәни байлыклар объектлары дәүләт тарафыннан саклана;

3.3.71. Матди булмаган этномәдәни байлык өлкәсендә төбәк фәнни-техник һәм инновацион программаларын һәм проектларын оештыруны һәм шул исәптән Татарстан Республикасының фәнни оешмалары тарафыннан гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

3.3.72. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган матди булмаган этномәдәни байлык өлкәсендәге фәнни һәм фәнни-техник программаларга һәм проектларга экспертиза уздыруны оештыра;»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.74 – 3.3.78 пунктчалар өстәргә:

«3.3.74. Матди булмаган этномәдәни байлык өлкәсендәге чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләүне тәэмин итә;

3.3.75. Матди булмаган этномәдәни байлык объектларын Реестрга кертү турында карар кабул итү өчен эксперт советы төзи, эксперт советы турындагы нигезләмәне һәм эксперт советы составын раслый;

3.3.76. «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пункт-

часында каралган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне һәм «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне гамәлгә ашыра;

3.3.77. Ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормалары бирелгән башка норматив хокукый актларның үтәлешен ведомство контролендә тотуны гамәлгә ашыра;

3.3.78. Объектлар (территорияләр) милекчеләре булган яки аларны башка законлы нигездә файдаланган дини оешмалар тарафыннан объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү буенча оештыру һәм башка чараларны үтәү, шулай ук ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрне үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.»;

5.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясен төзү турында» 2006 ел, 17 апрель, 183 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 июнь, 260 нчы; 2012 ел, 22 сентябрь, 791 нче; 2012 ел, 24 октябрь, 903 нче; 2020 ел, 8 декабрь, 1104 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясе турындагы нигезләмәнең 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган ЮНЕСКО эшләре буенча Татарстан Республикасы комиссиясе составында:

Комиссия составыннан Е.А.Барабанованы, Т.Д.Сөләймановны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Ринат Наил улы Садыйковны;

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Анастасия Валерьевна Софьинаны;

Олеся Александровна Балтусованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча)»;

Татьяна Петровна Ларионованың вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты (килешү буенча)»;

Нэлла Матвеевна Пруссның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТИСБИ» идарә университеты» югары белем бирү учреждениесе президенты».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Китапханәләрдән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 679 нчы; 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2016 ел, 19 декабрь, 951 нче; 2018 ел, 4 декабрь, 1082 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2020 ел, 10 апрель, 270 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Китапханәләрдән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль архив агентлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, фәнни оешмаларда башка архив документларын саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 мартындагы 24 номерлы боерыгы;»;

егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;»;

5.2 пунктның 5.2.1 пунктчасындагы унберенче абзацында «2014 – 2022 елларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган янгын куркынычсызлыгы таләпләренә; «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган янгын куркынычсызлыгы таләпләренә; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарына;»;

XIII бүлекнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хакимияте органнары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

14.2 пунктта «керем бирә торган эшчәнлекне» сүзләрен «эшмәкәрлек эшчәнлеген» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2014 ел, 1 ноябрь, 832 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче; 2018 ел, 9 июнь, 441 нче; 2018 ел, 4 декабрь, 1082 нче; 2020 ел, 3 август, 644 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;»;

6.3 пунктның дүртенче абзацында «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

11.1 пунктның таблицасында:

1 пунктның 5 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8-НК номерлы форма буенча «Музей эшчәнлеге турында белешмә» хисабы»;

2 пунктның 5 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8-НК номерлы форма буенча «Музей эшчәнлеге турында белешмә» хисабы»;

3 пунктның 5 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8-НК номерлы форма буенча «Музей эшчәнлеге турында белешмә» хисабы».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын, Спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын, Цирк программаларын күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 ел, 25 сентябрь, 871 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Концертлар һәм концерт программалары күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлектә:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Театрларда, концерт залларында, циркларда, зоотеатрларда, зоопаркларда һәм океанариумнарда эшләр башкарганда хезмәтне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 декабрендәге 914н номерлы боерыгы;»;

6.2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлектә:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Театрларда, концерт залларында, циркларда, зоотеатрларда, зоопаркларда һәм океанариумнарда эшләр башкарганда хезмәтне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 декабрендәге 914н номерлы боерыгы;»;

6.2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Цирк программаларын күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

II бүлектә:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы

карары;»;

6.2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин